ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) 4 өлештә «$4^1$ өлешендә» сүзләрен «$4^1$ һәм $4^{1-1}$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $4^{1-1}$ өлеш өстәргә:
«$4^{1-1}$. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрлары үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә анда үзе турындагы белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәсе әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килә торган айдан башлап алты календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Күпфатирлы йортның күрсәтелгән өлешендә урнашкан урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү

йөкләмәсе барлыкка килгән датадан башлап капиталь ремонт өчен кертемне күпфатирлы йортның күрсәтелгән өлеше эксплуатациягә тапшырылган датага кадәр мондый күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын булдыру алымын билгеләү турында кабул ителгән һәм гамәлгә ашырылган карар нигезендә, әгәр бу датадан соң мондый күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан башка карар кабул ителмәгән булса, түлиләр.»;

в) $4^2$ өлештә «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «, яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат милкенә,» сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяның $10^3$ өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^{1-1}$ өлеше нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрлары үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә анда үзе турындагы белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренә әлеге Закон үз көченә кергән көнгә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәрнең артык саналган һәм күрсәтелгән урыннар милекчеләре тарафыннан түләнгән суммасы (урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә бәйле рәвештә алар тарафыннан түләнгән пеняны да кертеп) автомат рәвештә аларның киләчәк чорга капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен үтәү исәбенә санала.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 01 март
№ 7-ТРЗ